Раслыйм
Казан шәһәре Мәскәү районының
муниципаль ияле мәктәпкәчә
белем бирү учреждениясе
“105 нче балалар бакчасы” мөдире
__________ Л.Р.Низамиева
__________ 2024 ел

Казан шәһәре Мәскәү районының
« Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче
105 нче номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы»
Муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең
**2024-2025 уку елына эш планы**

Педагогик берләшмә
утырышында кабул ителде
протокол №1
28.08., 2024 ел

**Мәгълумати белешмә**.

Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 105 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Урнашу урыны: 420095, Казан шәһәре, Бакалейная урамы, 10

Икенче категорияле балалар бакчасы.

Мөдире: Низамиева Лилия Рәшид кызы

Беренче квалификация категориясе

Балалар бакчасы 1971 нче елдан эшли.

Типовой проект буенча төзелгән, санитар-гигиеник һәм янгынга каршы таләпләргә туры килә торган кирпеч бинага урнашкан. Табигый һәм махсус ясалма яктырту нормаларга җавап бирә.

Балалар бакчасында бүгенге көндә 6 төркем эшли,

110 урынга исәпләнгән.

2022-2023 уку елына җыелган балалар саны - 140 бала.

6 төркемнең:

2 төркем – 2-3 яшькә кадәр

1 төркем — 3 -4 яшькә кадәр

3 төркем мәктәпкәчә яшьтәгеләр

2023– 2024 нче уку елында 13 педагог эшләде.

Шуларның:

9 тәрбияче, 4 специалист:

- өлкән тәрбияче
- муз. оештыручы
- укытучы -логопед
- педагог- психолог

Педагогик коллектив тулысынча педагогик белемгә ия.

Югары белем — 13 педагог- 85%

Махсус урта белем — 2 педагог- 15 %



Педагогларның квалификация категорияләре

13 педагогның аттестацияләнгән: 12 педагог - 92 %
Югары категорияле - 1 педагог – 7%
Беренче категорияле - 11 педагог-85 %
Яшь белгечләр - 1 педагог, бер педагог башкарган вызыйфасына туры килүгә аттестацияләнгән.




2023-2024 елда аттестация 1 педагог узды. Кадрларны урнаштырган чакта аларның психологик туры килүе, аттестация нәтиҗәләре, индивидуаль мөмкинчелекләре һәм иҗади потенциальлары исәпкә алына.

Балалар бакчасын методик тулыландыру мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институты белән тыгыз эшчәнлек алып бару белән бәйләнгән.

Педагоглар даими рәвештә мәгарифне үстерү институтында квалификация күтәрү курслары һәм аттестация узалар.

**2023 – 2024 нче уку елына анализ**.

Балалар бакчасының эшчәнлеге түбәндәге норматив- хокукый документлар нигезендә билгеләнә:

- РФ конституциясе
- РФ РТ белем бирү законы
- Балалар хокуклары конвенциясе
- Балалар бакчасының Уставы
- Федераль дәүләт белем бирү стандарты

Тәрбия- укыту эшен алып бару хокукы Казан шәһәрере администрациясе белем бирү идарәсе тарафыннан бирелгән 16Л01 серияле 0001416 нчы номерлы 22.08.2014 елгы лицензиясе нигезендә бирелә.

Балалар бакчасына кабул итү балалар бакчасы Уставында билгеләгән килешү нигезендә башкарыла.

Шулай ук балалар бакчасының Үсеш программасы да федераль дәүләт белем бирү стандартын исәпкә алып яңартылды. Ә әлеге уку елында балалар бакчасының Үсеш программасына "Киләчәк" стратегиясе кысаларында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча яңа УМКлар куллану буенча да үзгәрешләр кертелде.

2022-2023 нче уку елында балалар бакчалары өчен федераль белем бирү программасы гамәлгә кертелә башлый.

2024 елгы "Балалар бакчасы тарафыннан факт буенча күрсәтелгән муниципаль хезмәтләрнең стандартларга туры килүен тикшерү түбәндәге нәтиҗәләрне күрсәтте:

| № п/п | Хезмәтнең төре | Күрсәтелгән хезмәтнең күрсәткече | Стандартка туры килүе | Факт буенча күрсәтелгән хезмәт | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 2013-14 | 2014-15 |
| | «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү» һәм «Баланы балалар бакчасында тәэмин итү » | 2 тән 7 яшькә кадәр балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү белән тәэмин ителгән балалар | 80%тан артык | 100% | 100% |
| | | Сәламәтлек индексы | 28,1% тан ким түгел | 38% | 38% |
| | | Балаларның физик әзерлеге:<br><br>Югары<br>Уртача<br>Түбән | ким булмаска тиеш<br><br>26,4%<br>62%<br>11,6% | <br><br>62%<br>35%<br>3% | <br><br>63%<br>34%<br>3% |
| | | Бер баланың авырып калдырган көннәре саны | Елга 11 көннән артык түгел | 2,3 | 2,3 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | Балаларның мәктәптә укуга<br>әзерлеге:<br><br>югары<br>уртача<br>түбән | <br><br><br><br>71%<br>17%<br>12% | <br><br><br><br>86%<br>14%<br>- | <br><br><br><br>87%<br>13%<br>- |
| | | Аттестациялəнгəн педагоглар өлеше | 74% тан ким түгел | 81,25% | 71,5% |

Таблицадан күренгәнчә, аттестациялəнгəн педагоглар өлеше алдагы елда стандарттан югары булуы күренә. Шулай ук стандарттан югары булса да, узган ел белән чагыштырганда, бер баланың ел буена авырып калдырган көннәр саны кимегәнен күрәбез. Хәркөн иртән музыка залында төркемнәр иртәнге гимнастика комплексы ясады. Уку елы дәверендә шәфкать туташы һәрдаим оксолин мае белән балаларның борыннарын майлады, аскорбин кислотасы бирелде, йокыдан соң урыннарда килеш чыныктыру күнекмәләре ясалды, физик тәрбия шөгылләре өчен ясалган традицион булмаган коврилар өстеннән йөрделәр.

Балалар бакчасында ата- аналар һәм балалар составы ел саен үзгәреп торса да, безнең милли балалар бакчасында туган телне үстерү һәм саклау, татар телендә балаларның сөйләмен үстерү өстендә эшләү, балаларга милли тәрбия бирү безнең коллектив өчен мөһим бурычларның берсе булып кала бирә. Балаларның аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып белү тирәлеге киңәю һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның үз туган телен яхшы белүенә бәйле.

Уку елы дәверендә УМК буенча кулланмалар актив кулланып килде.Туган телне үстерү һәм телгә мәхәббәт тәрбияләүдә тәрбияче факторы да зур урын алып тора. Тәрбиячеләр А.Х.Шакурова, Г.М.Сибгатуллина, Э.М.Гимадиева, А.М.Мустафина, Л.Р.Хабибрахманова балаларның туган телдә аралашуы өчен барлык шартларны тудырырга тырышалар, туган телгә өйрәтүнең төрле алымнарын кулланалар.

«Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы буенча барлык татар төркемнәренең нәтиҗәләре түбәндәгечә булды:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗәдә, % | Уртача дәрәҗәдә, % | Түбән дәрәҗәдә, % |
|---|---|---|---|
| II кечкенәләр | | | |
| Уртанчылар | 7 | 59 | 34 |
| Зурлар | 32 | 50 | 18 |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме | 34 | 66 | 0 |

«Татарча сөйләшәбез” методик кулланмасы буенча рус телле балаларның татар телен белү нәтиҗәләре:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗәдә, % | Уртача дәрәҗәдә, % | Түбән дәрәҗәдә, % |
|---|---|---|---|
| Уртанчылар | 17 | 40% | 13% |
| Зурлар | 43% | 57% | - |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме | 45% | 55% | - |

«Изучаем русский язык” методик кулланмасы буенча татар балаларының рус телен белү дәрәҗәсе:

| Төркемнәр | Югары дәрәҗәдә | Уртача дәрәҗәдә | Түбән дәрәҗәдә |
|---|---|---|---|
| Уртанчылар | | | |
| Зурлар | 8 бала – 72% | 3 бала – 28% | - |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме | 8 бала – 72% | 3 бала – 28% | - |

Күрсәткечләрне тагын да яхшырту өчен, ата-аналар һәм балаларны туган телне өйрәнүгә тарту өчен түбәндәгеләрне планлаштыырабыз:

- Башка милләттән булган балалар һәм ата-аналарда да татар теленә хөрмәт һәм татар телен өйрәнүгә кызыксындыру тудыру максатыннан ата-аналар өчен туган телне саклау һәм үстерү турында консультацияләр, бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары уздыру.
- Тәрбиячеләр һәм белгечләргә татар телен өйрәнү һәм өйрәтү буенча тирәнтен эш алып бару.
- Балаларны туган телләрендә һәм икенче дәүләт телендә өйрәтү өчен яңа укыту-методик кулланмалар һәм яңа алымнар куллану.
-

Төркемнәрдәге балаларның милләт буенча бүленеше:

| № | Төркемнәр/ еллар | Татар балалары | Рус балалары |
|---|---|---|---|
| | | 2023-2024 | |
| 1 | I кечкенәләр төркеме 04 | 12 | 8 |
| 2. | 1 кечкенәләр төркеме 01 | 22 | 1 |
| 3. | II кечкенәләр төркеме | 21 | 4 |
| 4. | Уртанчылар | 21 | 5 |
| 5. | Зурлар төркеме | 16 | 7 |
| 6. | Мәктәпкә әзерлек төркеме | 19 | 5 |
| | Барысы | 111 | 30 |

Балалар бакчасына шулай ук 3 үзбәк, 1 азербайдҗан, 1 калмык баласы йөри.

Балалар бакчасында туган телне саклау һәм үстерү, программалар куллану буенча тәҗрибәбез белән район һәм шәһәр күләмендә уздырган методик берләшмәләрдә һәм чараларда һәрдаим катнашабыз.

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| | Киров һәм Мәскәү районнары татар телендә өйрәтү тәрбиячеләре өчен методик берләшмәсе: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм теле үсешендә фольклорның роле. Әкиятләр” 184нче балалар бакчасы | Ноябрь, 2023 |
| | Киров һәм Мәскәү районнары татар телендә өйрәтү тәрбиячеләре өчен методик берләшмәсе:”Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешендә декоратив-гамали иҗат”, 321 нче балалар бакчасы | Февраль, 2024 |
| 1 | Киров һәм Мәскәү районнары тәрбиячеләре өчен методик берләшмәсе:” Төрле материалларны күләмле формаларда кулланып декоратив рәсем ясау процессында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иҗади үсеше”, 321 нче балалар бакчасы | Декабрь, 2023 |
| 2 | Киров һәм Мәскәү районнары татар телендә өйрәтү тәрбиячеләре өчен методик берләшмәсе:”Юл йөрү иминлеге нигезләрен формалаштыру”, 321 нче балалар бакчасы | Февраль, 2024 |
| | Киров һәм Мәскәү районнары тәрбиячеләре өчен методик берләшмәсе:” Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып белү үсешендә заманча педагогик белем бирү технологияләрен куллану”, 321 нче балалар бакчасы | Март, 2024 |
| | Киров һәм Мәскәү районнары өлкән тәрбиячеләр төчен методик берләшмәсе:”Юл йөрү иминлеге нигезләрен формалаштыру”, 58 нче балалар бакчасы | Март, 2024 |

Һәр уку елында педагоглар алдына торган максатыбыз-сәламәтлекне саклауга юнәлтелгән программалар кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның физик һәм психик сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү.

Балалар белән түбәндәге чаралар уздырылды:

- Сәламәтлек турында шөгыльләр уздыру;
- Физкультура шөгыльләре, иртәнге гимнастика;
- Һәр шөгыль вакытында физминуткалар уздыру;
- Саф һавада уеннар, күңел ачу чаралары;
- Малайлар өчен атнага 1 тапкыр “Рубин” футбол түгәрәге;
- Балаларның көндәлек режимын төгәл үтәү, йокы, ашау, шөгыльләр;
- Көндезге йокыдан соң урыннарда килеш чыныктыру күнекмәләрен ясау;
- Ашаганнан соң һәрдаим авызны чайкау.

Төрле сәбәпләр аркасында балалар бакчасында балалар саны даими түгел, ә көн саен, ай саен үзгәреп, артып яки кимеп тора.

| Айлар | Балалар саны<br>%<br>2021-2022 | Балалар саны<br>%<br>2022-2023 | Балалар саны<br>%<br>2023-2024 |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | 69 | 69 | 70 |
| Октябрь | 69 | 70 | 72 |
| Ноябрь | 75 | 58 | 72 |
| Декабрь | 76 | 69 | 69 |
| Январь | 74 | 58 | 58 |
| Февраль | 69 | 66 | 70 |
| Март | 66 | 68 | 67 |
| Апрель | 65 | 70 | 74 |
| Май | 72 | 66 | 74 |
| Уртача | 70 | 66 | 70 |




Балаларның сәбәпсез бакчага килми калулары күпчелек очракта бакча сезоны вакытында сентябрь аенда, һәм февраль-март айларында күзәтелә. Алдагы уку елында балалар бакчасына түләү шартлары үзгәрү сәбәпле, бала бакчага йөрсә дә, йөрмәсә дә билгеле бер сумманы түләп барырга тиеш, шуңа күрә балаларның сәбәпсез бакчага йөрмәүчеләре нык кимеде. Ел дәвамында уртача 72% бала балалар бакчасына даими йөреп торалар.

2023-2024 нче уку елында март аенда балаларның бакчага йөрү % узган ел белән чагыштырганда сизелерлек аз булуы күренә. Шуңа күрә киләсе елда сәламәтлекне саклаучы технологияләр куллану бурычын тормышка ашырырга планлаштырабыз.

Балалар бакчасында берничә ел рәттән педагог- психолог Н.В.Гәйфетдинова җитәкчелегендә педагогик коллектив тарафыннан яңа килүче балалар һәм аларның ата-аналары өчен адаптация чорын җиңеләйтү максатыннан “Беренче адымнар” исемле программасы буенча эш алып барыла.

Кече яшьтәге балаларның адаптация чорының нәтиҗәләре

| еллар | Балалар саны | җиңел | | уртача | | авыр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | саны | % | саны | % | саны | % |
| 2021-2022 | 29 | 20 | 69% | 8 | 28% | 1 | 3% |
| 2022-2023 | 20 | 17 | 85% | 3 | 15% | 0 | 0 |
| 2023-2024 | 20 | 16 | 80% | 4 | 20% | 0 | 0 |

Эш тәҗрибәбез уңышлы килеп чыкты, балалар бакчага җиңел иялэшәләр, ата-аналар бакчадагы белгечләр, кагыйдәләр, үзенчшлекләр белән якыннан танышалар, үз теләк һәм фикерләрен белдерә алалар.

Алдагы уку елында шәһәр күләмендә балалар бакчасының тормышын яктырту, эш тәҗрибәсен башкаларга күрсәтү, ата-аналар белән һәрдаим аралашу өчен балалар бакчасының сайты булдырылды. Сайтта бакча турында, кулланылучы программалар, педагоглар турында мәгълумат, уздырылучы чаралар ел дәвамында яктыртылып барылды.

Балалар бакчасының тәрбия һәм белем бирү юнәлешләренең берсе булып балаларда сөйләм кимчелекләрен төзәтү тора. Узган уку елында балалар бакчасында бер логопедик төркем эшләде. 14.05.2024 елның ПМПК карары №13 нигезендә, логопедик төркемгә 12 бала кабул ителде: 1 бала ФФН диагнозы, 13 бала ОНР диагнозы белән кабул ителде, логопедия төркеменнән 9 бала чыгарылды: 6 бала чиста сөйләм белән, 3 бала сизелерлек үзгәрешләр белән мәктәпкә киттеләр. 12 бала укуларын дәвам итәр өчен икенче елга калдырылдылар, логопедия төркемендә барысы 24 бала шөгыльләнәчәк. Елдан-ел балалар арасында логопед ярдәменә мохтаҗ балалар саны артуы күзәтелә. Без моның сәбәпләрен балалар белән аз аралашу, күбрәк телевидение һәм компьютер йогынтысыннан




күрәбез.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның дөрес туклануы нормаль физик үсешенә зур йогынты ясый һәм ул дөрес оештырылырга тиеш.

Яңа уку елында балаларның азыгын төрлеләндерү, витаминнарга баету, яшелчә ашларына балаларның игътибарын җәлеп итү буенча медицина белгечләре, поварларның уртак эшен оештыру мәсьәләсен планлаштырабыз.

Шулай ук ел дәвамында менюга үзгәрешләр кертү буенча да эш алып барылды.

Ата-аналарның үтенечләре буенча, безнең балалар бакчасында ризык әзерләү өчен хәләл ит кулланыла.

Ел дәвамында төп ашамлыклар: ит, май, шикәр, балык, сыр, он, ярмалар нормада бара, ә яшелчәләр нормадан аз бирелә, чөнки безнең балалар бакчасында салатлар әзерләү цехы юк.

Балаларга икенче иртәнге аш итеп сок бирү, күбрәк җиләк-җимешләр куллану аша план һәм факт арасындагы аерманы киметү өстендә эш алып барабыз.

Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә май аенда 13.05.2024 елгы приказ №17 нигезендә фронталь тикшерү үткәрелде. Тикшерүдә балалар бакчасы мөдире Л.Р.Низамиева, өлкән тәрбияче Л.Р.Хабибрахманова, педагог-психолог Н.В.Гәйфетдинова, шәфкать туташы Г.И.Шәяхмәтова, тәрбияче А.М.Мустафинадан торган комиссия балалар бакчасы буенча фронталь тикшерү һәм өйрәнүләр оештырылды.

Төркемдә ел дәвамында тәрбиячеләр Г.И.Хисматуллина һәм Р.Г.Шакирзянова эшләделәр. Тәрбиячеләрнең төп эш юнәлеше— сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү һәм юл кагыйдәләрен өйрәтү аша балаларның сәламәтлеген ныгыту һәм танып белү эшчәнлеген үстерү. Мәктәпкә әзерлек төркемендә барлыгы 24 бала йөри, шуларның 24 бала мәктәпкә китәчәк.

Фронталь тикшерү вакытында шөгыльләр һәм режим моментларының, уку һәм үсеш тирәлегенең оешырылуына, тәрбиячеләрнең документация белән эшенә, тәрбиячеләр, балалар, ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләргә, балаларның һәр төрле эшчәнлек буенча программа материалын үзләштерүенә, авыручы балалар саны һәм аларның сәбәпләренә төп игътибар юнәлтелде.

Тикшерү буенча түбәндәгеләр ачыкланды.

Һәрьяклап үсеш һәм мәктәптә уңышлы укуга әзерләү өчен шартлар:

- Төркемдә балаларның һәрьяклап үсеше һәм мәктәптә уңышлы укуга әзерләү өчен шартлар тудырылган. Уеннар һәм уенчыклар, күрсәтмә һәм дидактик материал балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә. Кулның вак моторикасын үстерүгә уеннар күп тупланган, логик фикерләүне үстерүче уеннар арттыруга игътибарны юнәлтергә кирәк.
- Укыту-тәрбия эше программа таләпләренә туры китерелеп алып барыла, көндәлек режим саклана. Балалар гади культура- гигиена күнекмәләрен һәм үз-үзләренә мөстәкыйль хезмәт күрсәтү алымнарын беләләр. Киемнәренең тышкы килешенә, төркемдәге әйберләрнең тәртиптә булуына игътибар итәләр.
- Төркемдә һава режимы саклана, балалар җиңел киемнәрдән йөриләр.

Хезмәт тәрбиясе буенча эш яхшы оештырылган. Балалар эшне бүлешеп, чираттан эшли беләләр. Ашарга әзерләгәндә, табигать почмагында эшләгәндә, шөгыльләргә әзерләгәндә һәм аннан соң көчләреннән килгәнчә ярдәм итәләр.

Балаларның программа материалын үзләштерүе:

- Балалар әйләнә-тирәне танып белү һәм сөйләм теле буенча белемнәре программа таләпләренә туры килә. Балалар үзләре, әти-әниләре, яшәү урыннары турында сөйли беләләр. Тирә-юньдәге кешеләр хезмәте, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәре югары һәм уртача дәрәҗәдә, бары тик 10% кына түбән дәрәҗәдә.

| Балаларның белем һәм күнекмәләре дәрәҗәләре | Балалар саны | % |
|---|---|---|
| Югары | 9 | 36% |

| | | |
|---|---|---|
| Уртача | 12 | 52% |
| Түбән | 3 | 12 % |

- Санау, саннарның составы, геометрик фигуралар, ике, дүрт өлешкә бүлү, киңлеккә, озынлыкка үлчәү, мәсьәләләр төзү буенча белемнәре ныклы, дөрес җаваплар бирәләр. 60% югары, 35% уртача, 5% түбән.
- Рәсем ясау, кисеп ябыштыру, әвәләү, кул эше шөгыльләренә зур игътибар бирелә. Балалар эшләре күргәзмәсе ата-аналар өчен уңайлы итеп оештырылган.
- Саф һавада хәрәкәтле уеннар, чыныктыру процедуралары уздыруга җитәрлек игътибар бирелми.

Төркемдәге мөнәсәбәтләр.

- Тәрбияче һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр бер-беренә ярдәм итүгә корылган. Тәрбиячеләр балаларга ярдәм итү, балаларның яшь һәм характер үзенчәлекләренә туры килгән эш төрен сайлый белә. Балалар арасында килеп туган конфликтлы мәсьәләләрне ике якка да зыян китерми торган итеп чишергә тырышалар. Балаларның мөстәкыйльлеген үстерү буенча эш алып барыла.
- Ата-аналар, тәрбиячеләр һәм махсус белгечләр арасында мөнәсәбәтләр уңай. Ата-аналар барлык эш төрләрендә тәрбиячеләргә ярдәм итәргә әзер. Балалар бакчасында уздырылган чараларда актив катнашалар, костюмнар, күрсәтмә материал әзерлиләр.

Документлар белән эш:

- Укыту-тәрбия планы таләпләргә туры китерелеп, чиста, пөхтә алып барыла. Шөгыльләрнең темалары, максатлары, көне буе уздырылачак режим моментлары, саф һавада булу, ата-аналар белән һәм балалар белән шәхси эш тәрбиячеләр тарафыннан тирәнтен уйлап планлаштырыла.
- Балаларның килү- килмәвен, сәбәпләрен билгеләп бару өчен махсус журнал бар. Ул һәркөн иртән тәрбиячеләр тарафыннан тутырыла.
- Ата-аналар турында, балаларның яшәү урыннары турында белешмәләр төгәл һәм тулы.

Тикшерү ахырында түбәндәге рекомендацияләр бирелде:

- Балаларның уен эшчәнлеген төрләндерү һәм тулыландыру буенча эш алып барырга.
- Балаларның туган телләрендә сөйләм телен үстерүгә игътибарны арттырырга.
- Саф һавада физкультра белән шөгыльләнү һәм күзәтүләр алып баруны системалаштырырга;
- Тәрбиячеләргә үз эшләрендә күбрәк заманча технологияләр кулланырга, диагностика өчен материал тупларга;
- Аерым балалар белән шәхси эшкә игътибарны арттырырга.

Балаларның соңгы елларда татар сыйныфларында
белем алуы турында белешмә

| Еллар | Балалар саны | Алардан татар классларында |
|---|---|---|
| 2022 | 23 | 5 |

| | | |
|---|---|---|
| 2023 | 50 | 8 |
| 2024 | 24 | 5 |




Мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар мәктәп һәм гимназияләрдә укуларын дәвам итәчәкләр. Аларның нинда мәктәпләрдә укуларын дәвам итүләре һәм ничек укулары белән һәрдаим кызыксынып торабыз.

Татар мәктәпләрендә белем алуын дәвам итүче балалар саны аз булуы күзәтелә. Сәбәпләрен түбәндәгеләрдән күрәбез:

1. Якын тирәдә татар гимназияләре булмавы;
2. Ата-аналар татар телен үзләре тирәнтен белмәү сәбәпле балаларына ярдәм итә алмаудан кыенсынулары;
3. Югары уку йортларына кабул итү имтиханнары рус телендә булганлыктан, рус мәктәбендә уку яхшырак дигән фикер яклылар күп булу.

Уку елы дәвамында 2 тематик тикшерү уздырылды:

105 нче балалар бакчасының 2023-2024нче еллык эш планы буенча , 2023 елның 8 ноябрендәге 45 номерлы «балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча профилактика эшен оештыру» боерыгын үтәү йөзеннән мәктәпкәчә төркемнәрдә әлеге эш юнәлеше тикшерелде.

**1.Максат:** Максат: Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү һәм балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау буенча тәрбия-белем бирү эшенең нәтиҗәлелеген билгеләү ДОУ.

**Инспекция юнәлешләре**:

• укытучының һөнәри осталыгын бәяләү;
• педагогның эшен календарь-тематик планлаштыру;
• балаларның белемнәрен, осталыкларын, күнекмәләрен тикшерү;
• ата-аналар белән эшләү;
• төркемдә, методик кабинетта шартлар тудыру

**Инспекция ысуллары**:

• турыдан-туры белем бирү эшчәнлеген анализлау;
• тәрбиячеләр белән әңгәмә;
• календарь-тематик планлаштыруны анализлау;
• балаларның белем бирү эшчәнлеге процессындагы эшчәнлеген анализлау, күңел ачу, КВН.
• ата-аналар анкетасын анализлау;
• төркемнәрдә предмет-үсеш мохитен анализлау.

I Еллык бурычка ярашлы рәвештә чаралар планлаштырылган һәм үткәрелгән:
1.Консультацияләр.
2.Юл хәрәкәте темалары буенча ата-аналар клублары дистанцион рәвештә узды.
3. Педагоглар өчен семинар-практикум
4.Тематик атнаю
Тематик атна кысаларында: Урта төркем балалары өчен «Светофор иленә сәяхәт» күңел ачу. «Минем әнием – автоледи»
Әниләр көненә багышланган ата-аналар өчен чара.
Супер балалар әзерлек төркемендә балалар рәсемнәре күргәзмәсе» юл һәм мин »Зебра " Акциясе Акция кысаларында балалар бакчасының өлкән һәм әзерлек төркемнәрендә чаралар уздырылды:5. «Балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча профилактика эшен оештыру»тематик контроль
Тематик контроль графигы буенча дәресләргә йөрү Диагностикасы
Урта, өлкән һәм әзерлек төркемнәрендә диагностика үткәрделәр.

**Нәтиҗә:**
Барлыгы: 96 бала
Югары дәрәҗә: 0
Уртачадан югарырак: 22 бала 23%
Уртача дәрәҗә: 32 бала 33%
Уртача 6 11 бала 12%
Түбән дәрәҗә: 31 бала 32%
Ата»аналар анкетасы "сак булыгыз" «Юлларда мәктәпкәчә яшьтәге балаларның куркынычсыз тәртибе мәсьәләләрендә педагогик компетентлык»балалар бакчасы педагогларына анкета
Тәрбия-белем бирү эшен планлаштыру: Тематик контроль барышында перспективалы һәм календарь планнары тикшерелде.
**Тәкъдимнәр:** 1. Тәрбия-белем бирү эшен «Солнышко» ДОУНЫҢ «педагог документациясе турында нигезләмә» таләпләренә, эстетик нормаларга һәм ФГОСка ярашлы планлаштырырга.
2. Төрле эшчәнлек төрләрен рациональ һәм тигез планлаштырырга, атна темаларына зур игътибар бирергә.
3.Тематик дәресләр һәм күңел ачулар планлаштыруны һәм үткәрүне дәвам итегез
**Предмет-үсеш мохите**.
Шулай ук предмет-үсеш хәрәкәт итү мохитен булдыру буенча шартлар тикшерелде.
Төркемнәрнең барлык педагоглары «Иминлек почмагы» һәм ата-аналар өчен ачык мәгълүмат тәкъдим иттеләр, юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча дидактик һәм күзаллау материалларының төрлелеген күрсәттеләр , мәгълүмати почмакларны бизәүдә иҗади якын килү һәм оригинальлек күрсәттеләр.
Юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча почмаклар санитар һәм яшь таләпләренә туры килә. Барлык материал эстетик нормаларга туры китереп эшләнгән.
Әзерлек төркемендә, өлкән, урта төркемнәрдә материал ирекле рәвештә кулланыла.
Белем бирү эшчәнлеге.
ОБЖ буенча турыдан-туры белем бирү эшчәнлеген оператив контроль нәтиҗәләре буенча җитди искәрмәләр булмады.
Дәресләр планлаштыру буенча үткәрелә, дуслык һәм тыныч шартларда уза. Тәрбиячеләр методик яктан балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, структураны төгәл үтәп, дәресләрне дөрес үткәрәләр.
Төрле ысуллар һәм алымнар киң кулланыла.
Барлык дәресләр дә балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә, интеграцияләнгән. Тәрбиячеләр дәрескә әзерләнүгә җаваплы карыйлар. Дәресләрдә барлык максатлар чагыла. Максатлар темага һәм программа эчтәлегенә туры килә.
Дәресләрдә балалар куелган барлык бурычларны үти.
Ләкин дәрестә балалар һәрвакытта да оешкан һәм тәртипле түгел.

**Тәкъдимнәр:**

Дәрестә оешканлыкка һәм дисциплинага зур игътибар бирегез:

- балаларны тыныч кына утырырга һәм игътибар белән тыңларга өйрәтү. өлкән төркемнәрдә кычкырмаска, өзмәскә, кул күтәрмәскә.

Ата-аналар белән эш.

I. балалар бакчасында ата-аналар белән эш планлаштырыла һәм алып барыла.

1. Барлык төркемнәрдә дә перспективалы план еллык бурычларга туры килә һәм барлык планлаштыру таләпләренә җавап бирә.

2. Ел дәвамында ата-аналар өчен стендлар вакыт-вакыт үзгәрә. Барлык мәгълүмат эстетик рәвештә рәсмиләштерелә һәм кабул итү һәм уку өчен ачык.

Тематик контроль чорында барлык тәрбиячеләр дә ата-аналарга ОБЖ темасына мәгълүмат бирмәгән.

3.Мәгълүмат балалар бакчасы сайтында урнаштырылмый.

**Карар**

1. Тәрбия-белем бирү эшен «Солнышко» ДОУНЫҢ «педагог документациясе турында нигезләмә» таләпләренә, эстетик нормаларга һәм ФГОСка ярашлы планлаштырырга.

2. Гомуми программа бурычларына һәм ДОУНЫҢ еллык бурычларына ярашлы рәвештә төрле эшчәнлек төрләрен рациональ һәм тигез планлаштырырга. Дәресләрне әзерләүгә һәм үткәрүгә зур игътибар бирергә.
3. ОБЖ программасын эшләп бетерү. Белем бирү учреждениесе программасына һәм ФГОС таләпләренә ярашлы рәвештә 2 кече төркемнән бер елга ОБЖ буенча перспективалы планнар төзергә.
4. Методик кабинет һәм төркемнәрнең юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча үсеш мохитен тулыландырырга.

2. Балалар бакчасында “ФГОС таләпләренә туры китереп балалрны ике дәүләт теленә өйрәтү өчен УМКның кулланышы” буенча тематик тикшерү 15.02.2023 елның , №6 боерык нигезендә үткәрелде.

Үткәрү вакыты: 16 нче февраль- 22 нче февраль, 2023 ел.

Максат: балалар бакчасында ФГОС таләпләренә туры китереп балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү өчен УМКның кулланылышын тикшерү.

Тикшерү түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды:

- төркемнәрдә эш планнарында белем бирү өлкәләренең чагылышы;
- төркемнәрдә балалар белән аралашу;
- мультимедиа ресурсларын кулану;
- УМК буенча ата-аналар өчен мәгълүмат;
- УМК буенча дидактик уеннар;
- Предметлы-үсеш тирәлегенең функциональлеге.
- «Туган җирем татарстан” почмакларының торышы

Тематик тикшерү комиссиясе составы: Л.Р.Низамиева, Н.В.Гәйфетдинова, А.М.Мустафина, Л.Р.Хабибрахманова.

Тикшерү барышында түбәндәге ачыкланды:

- Төркемнәрдә эш планнарында УМК буенча кулланылган уеннар, материал еш чагылыш ала. Тәрбиячеләр Гильфанова Г.И, Шакурова А.Х., Гимадиева Э.М., Хисматуллина Г.И. планнары уңай яктан билгеләп була.Алар һәр көнне балалар нинди сүзле уеннар уйныйлар, нинди шигырьләр өйрәнәләр, нинди методик кулланмаларны файдалануларын төгәл күрсәтеп баралар.

- Төркемдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең үзара аралашуына килгәндә, тәрбиячеләр барысы да балалар белән күбрәк татар телендә аралашалар. Хисматуллина Г.И., Сабирова Г.А.га күбрәк татар телендә аралашырга кирәк. Гимадиева Э.М, Каримова Г.Г., Шакурова А.Х., Гильфанова Г.И. балаларның да үзара татар телдә сөйләштеререгә тырышалар. Балалар үзара күпчелек очракта рус телендә
- Мультимедия ресурсалыр тәрбиячеләр хәрдаим кулланып киләләр. Сөйләм теле, әйләнә-тирә белән танышу, матур әдәбият белән танышу шөгыльләрендә анимацион сюжетлар, мультфильмнар, президентация кулланалар. Татар теле тәрбиячесе узенең эшендә дидактик уеннарны мультимедия ресурсалыр аша үткәрә.
- Ата-аналар өчен почмакларның торышы буенча зур кисәтүләр булмады. Икенче кечкенәләр төркеменнән алып һәр төркемдә ата-аналар өчен УМК буенча төсле тулы мәгълумат урнаштырылган. Ата-анлар өчен консультацияләр күбесенчә татар телендә булсалар да, күбесен яңартырга кирәк.
- УМК буенча дидактик уеннарны яшь үзенчәлекләре туры китереп җитәрлек күләмдә ясалган. Балалар режим моментларында теләп дидактик уеннарны алып уйныйлар.
- Төркемнәр чиста, якты, зәвыклы итеп җиһазланган. Предметлы-үсеш тирәлегендә баларга уйнар өчен кирәкле җиһазлар, уенчыклар булдырылган.
- “Туган җирем Татарстан” почмакларының паспорты һәр төркемдә дә булдырылган. Яшь үзенчәлекләренә материал туры килә, ләкин төркемнәрнең почмакларында рус киемле малай, Мәскәү турында белешмә һәм рәсемнәр юк.Төркемнәргә курчакны һәм материалны кыска вакыт аралыгында булдырыга киңәш螺 ителде.

Оператив контроль “Балаларның уен эшчәнлеге”, “Физкультура шөгыльләре”, “Татар телендә аралашу”, “Балаларны әдәби әсәрләр белән таныштыру”, “Төркемнәр һәм мәйданчыкларның җәйге чорга әзерлеге” темалары буенча уздырылды.

Балалар бакчасы коллективы 2023-2024 нче уку елында расланган план буенча эш алып барды. Планда балаларның һәрьяклы шәхси үсеше өчен индивидуаль үзенчәлекләре исәпкә алынды. Узган елга йомгак ясап, коллектив куелган максатларны өлешчә үтәде дип әйтә алабыз һәм түбәндәге нәтиҗәләрне чыгарабыз:

- Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча УМКлар кулланылды;
- Балалар бакчасында уздырылган чаралар аша балаларның туган телләрендә сөйләм телен үстерү буенча эш алып барылды;
- Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру буенча эш дәвам итте;
- Балалар бакчасының белем бирү программасы төзелде һәм расланды.
- Педагогларның педагогик сәләтләрен, эшкә мөнәсәбәтләрен һәм белем, күнекмәләрен төрле конкурслар һәм ярышларда катнашу, үзбелемнәрен арттыру аша башкарылды.

Административ - хуҗалык эшләре план буенча уздырылды, матди ярдәм мәгариф бүлеге тарафыннан һәм ата-аналар тарафыннан күрсәтелде:

1. Үзебезнең көч белән яңа ел костюмнары яңартылды.

Планлаштырылган, әмма үтәлми калган эшләр:

1. Финанслау булмау сәбәпле мәйданчыклардагы инвентарь алышынмады.

Әлеге эшләр финанс мөмкинчелекләре булмау сәбәпле, быелгы уку елында тормышка ашмадылар, аларны киләсе елны башкарып чыгарга планлаштырабыз.

2024-2025 нче уку елына балалар бакчасының
техник базасын тулыландыру буенча эш планы

| № | Эшнең эчтәлеге | вакыты | җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Уеннар һәм уенчыклар булдыру | Ел буе | Бакча мөдире |
| 2. | Хуҗалык кирәк-яраклары алу | Мөмкинчелектән чыгып | Бакча мөдире |
| 3. | Уен мәйданчыкларында күләгәле верандалар буяу | Мөмкинчелектән чыгып | Бакча мөдире, ата-аналар комитеты җитәкчесе |

2023-2024 нче елда куелган бурычларны анализлап, куелган максатлар расланган план буенча үтәлде дип әйтергә була һәм шулардан чыгып

Сентябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнәрнең яңа уку елына әзерлеген тематик тикшерү | 1 нче атна | Бакча мөдире, комиссия |
| 2. | Иҗади төркемнәрнең эш планнарын раслау | 2 нче атна | Бакча мөдире |
| 3. | «Балаларның социаль адаптациясе: мәсьәлә һәм чишелеш” | 3 нче атна | Н.В.Гайфетдинова |
| 4. | Балаларның интегратив сыйфатлары формалашуга һәм белем бирү өлкәләре буенча күнекмәләргә мониторинг уздыру | 2-3 нче атна | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 5. | «Минем җәйге ялым»<br>Балалар рәсемнәре | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 6. | Ата-аналар өчен консультация «Балаларның балалар бакчасына ияләшүе» | 3 нче атна | Г.Г.Каримова |
| 7 | Балаларның өстәмә шөгыльләргә йөрүен оештыру | 2 нче атна | Өлкән тәрбияче |

Октябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Өлкәннәр көне уңаеннан чаралар уздыру | 1 нче атна | Л.А.Рафикова |
| | | | |
| 3. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Логопедиядә сәламәтлекне саклауга юнәлтелгән технологияләр куллану» “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга юлда йөрү кагыйдәләренә өйрәтү” | 2 нче атна | Э.Р.Пыгина |
| 4. | Ата-аналар өчен консультация «Уйнаганда дусларча мөнәсәбәтләр тәрбияләү» | 3 нче атна | Шакурова А.Х. |
| | Конкурс «Макет избы» | | |
| 5. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Табигать һәм хыял” | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 6. | Балалар цчен  УМК буенча Щкият кърсщтъ | 1 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 7. | «Уенчыклар белән бүлешергә өйрәнәбез» ата-аналар өчен консультация | 2 нче атна | Сабирова Г.А. |
| 8. | ПДД почмакларына конкурс | 4 нче атна | Комиссия |

Ноябрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | «Балаларны урамда йөргәндә кирәкле булган тәртипкә өйрәтү» ата-аналар өчен консультация | 2 нче атна | Шакирзянова Р.Г.. |
| 2. | Тәрбиячеләр өчен консультация “Әгәрдә төркемдә инфекция булса…” | 1 нче атна | Г.Р.Латипова |
| 3. | Көзге бал  бәйрәмнәрен уздыру | 1 нче атна | Тәрбиячеләр |
| 4. | Ата-аналар өчен консультацияләр<br>- «Салкын тию авыруларын кисәтү» | 3 нче атна | Г.Н.Камалова |
| 5. | Оператив тикшерү<br>«Әйләнә-тирә белән танышу шөгыльләре» | 1 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |
| 6. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Минем иң якын кешем әнием» | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Әниләр көненә багышланган чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 8. | Тематик тикшерү<br>«ФГОС таләпләренә туры китереп балаларны танып белү өлкәсен өйрәтү » | 2 нче атна | Комиссия |
| 9. | Педагогик киңәшмә уздыру<br>«Федераль дәүләт  стандартлары кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып белү һәм иҗади сәләтләрен проект һәм тәҗрибә эшчәнлек аша үстерү » | 4 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |

Декабрь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы Кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагогларның аттестациягә әзерләнүе һәм аттестация узуы | 2-3 нче атна | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 2. | «Иң яхшы Яңа елга бизәлгән төркем» конкурсы уздыру | 3 нче атна | комиссия |
| 3. | Кышкы мәйданчыклар конкурсында катнашу | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 4. | Хезмәткәрләр арасында яңа ел бәйрәмен уздыру буенча инструктаж үткәрү | 3 нче атна | Бакча мөдире |
| 5. | Ата-аналар өчен консультация<br>«Кызыклы математик материалның балаларның бөтен яктан да үсешенә әһәмиятлелеге»<br>«Кыш көнне майданчыкта йөреп керүне планлаштыру» | 3 нче атна | Г.И.Хамидуллина<br>Г.И.Гильфанова |
| 6. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Яңа елны көткәндә» | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Яңа ел бәйрәменә чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 8. | Тәрбиячеләргә консультация “Балалар белән танып белү өлкәсендә шәхси эш оештыру” | 1 нче атна | өлкән тәрбияче |
| 9. | Оператив тикшерү “Яңа ел бәйрәменә әзерлек һәм үткәрү | 3 атна | өлкән тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чаралары” | | |

Январь

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Юл йөрү куркынычсызлыгы кагыйдәләрен өйрәнү почмакларына смотр- конкурс | 3 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |
| 2. | Салкын тию авыруларын кисәтү буенча чаралар уздыру | 1-2 нче атна | Г.Н.Камалова |
| 3. | Тәрбиячеләр өчен семинар-практикум уздыру «Уйнап үсәбез» | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 4. | Тәрбиячеләр өчен консультация “Аралашмаучан бала: әлеге проблеманы бергә чишәбез” | 1 нче атна | Н.В.Гәйфетдинова |
| 5. | Ата-аналар өчен консультация: «Балаларның хәрәкәт эшчәнлеген оештыру» «Дөрес сөйләм формалаштыруда вак моториканың роле» | 1 нче атна | Г.М.Сибгатуллина Э.Р.Пыгина |
| 6. | Оператив тикшерү «Танып белү өлкәсе буенча дидактик уеннарның булуы» | 3 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |
| 7. | «Кышкы матурлык» балалар рәсемнәре күргәзмәсе | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Ата-аналар өчен консультация “Экология һәм сәламәтлек” | 2 нче атна | Р.А. Хасанова |

Февраль

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагогик киңәшмә уздыру:«Балаларны 2 дәүләт теленә өйрәтү буенча УМКның кулланышы» | 4 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |
| 2. | “Туган җирем Татарстан ” үзәкләрен тикшерү | 2 нче атна | Комиссия |
| 3. | Ватанны саклаучылар көне уңаеннан чаралар уздыру. | 3-4 нче атна | С.Ш.Симаева |
| 4. | Тәрбиячеләр өчен консультация «Игра на публику: как справляться с детскими вспышками агрессии?» | 1 нче атна | Н.В.Гәйфетдинова |
| 5. | Ата-аналар өчен консультация «Балалар бакчасында театраль эшчәнлек » | 1 нче атна | А.М.Шакирзянова |
| 6. | «Минем яраткан әтием» балалар рәсемнәре күргәзмәсе | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 7. | Түгәрәкләргә йөрүче балаларның иҗади отчеты | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 8. | Тематик тикшерү «ФГОС таләпләренә туры китереп балаларны ике дәүләт теленә төшендерү» | 3 нче атна | комиссия |

Март

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | 8 Март бәйрәме уңаеннан чаралар оештыру | 2 нче атна | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 2. | Язгы Здравиада бәйрәме оештыру | 4 нче атна | Тәрбиячеләр |
| 3. | Нәүрүз бәйрәме үткәрү | 3 нче атна | Иҗади төркем |
| 4. | Ата-аналар арасында анкета уздыру «Балалар бакчасы тәкъдим иткән хезмәтләр белән кәнәгатьлекне ачыклау» | 2 нче атна | Бакча мөдире |
| 5. | Тәрбиячеләр өчен консультация “Баланы кайчан һәм ничек укырга өйрәтергә” | 1 нче атна | Э.Р.Пыгина |
| 6. | Ата-аналар өчен консультация «Интернет ресурсларны дөрес файдалану» | 3 нче атна | Г.И.Хәмидуллина |
| 7. | Оператив тикшерү «Режим моментларында сәламәтләндерү чаралары уздыру» | 1 нче атна | Л.Р.Низамиева өлкән тәрбияче |
| 8. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Минем яраткан әнием» | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Семинар-практикум: « Формирование соц-ком качеств через двигательную активность в работе по | 4 нче атна | Комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | обучению пдд» | | |

Апрель

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкә әзерлек төркемендә фронталь тикшерү үткәрү | 2-3 нче атна | комиссия |
| 2. | Ата-аналарның гомуми җыелышы | 3 нче атна | Бакча мөдире |
| 3. | Төркемнәрдә ата-аналар очрашулары уздыру | 3 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 4. | Төркем тәрбиячеләренең иҗади отчеты | 2 нче атна | Л.Р.Низамиева |
| 5. | Тәрбиячеләр өчен консультация “Сөйләм телен үстерү өчен шартлар тудыру” | 1 нче атна | Л.Р.Хабибрахманова |
| 6. | Ата-аналар өчен консультация «Яшь үзенчәлекләренә туры китереп балаларның уен тирәлеген оештыру» | 3 нче атна | Р.А.Хасанова |
| 7. | Бөтендөнья сәламәтлек көнен билгеләп үтү | 2 нче атна | Н.В.Гәйфетдинова, Г.Н.Камалова |
| 8. | Балалар рәсемнәре күргәзмәсе «Бөек җиңүне каршылап» | 1 нче атна | Иҗади төркем |
| 9. | Г.Тукайнын туган көне уңаеннан чаралар уздыру | 4 нче атна | Иҗади төркем |
| 10. | Гомуми шәһәр өмәсендә катнашу | 4 нче атна | Коллектив |

Май

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагогик киңәшмә «2016-2017 уку елына йомгак ясау» | 2 нче атна | Л.Р.Низамиева |
| 2. | Җиңү көненә багышланаган чаралар уздыру | 1-2 нче атна | С.Ш.Симаева |
| 3. | Физик һәм танып белү эшчәнлегенә диагностика уздыру | 2-3 нче атна | Төркем тәрбиячеләре |
| 4. | Мәйданчыкларны һәм төркемнәрне җәйге чорга әзерләү | 1-3 нче атна | Бакча мөдире |
| 5. | Тәрбиячеләр өчен консультация “Ком һәм су белән күзәтүләр һәм тәҗрибәләр” | 1 нче атна | Р.Т.Алеева |
| 6. | Оператив тикшерү «Төркемнәр һәм мәйданчыкларның җәйге чорга әзерлеге» | 3 нче атна | комиссия |
